КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 ноябрь г.Казань № 1037

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 23 август, 690 нчы карары белән расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә раслау

турында» 2024 ел, 23 август, 690 нчы карары белән расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«күчемсез мөлкәтне (торак булмаган бинаны) карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (хезмәт урыннарын җыештыру; вентиляция, лифт, локаль челтәрләр һәм видеокүзәтү системаларына, су белән тәэмин итүнең һәм канализациянең йорт эчендәге системаларына, үзәктән җылыту, электр белән тәэмин итү системаларына, автоматлаштырылган янгын сигнализациясе системаларына техник хезмәт күрсәтү, файдалану мөмкинлеген һәм саклау сигнализациясе контрольдә тоту системасына хезмәт күрсәтү) буенча хезмәтләргә түләү;

күчемсез мөлкәткә (торак булмаган бинага) хезмәт күрсәтү буенча коммуналь хезмәтләргә (җылылык, су, энергия белән тәэмин итүгә) түләү;

күчемсез мөлкәтне (торак булмаган бинаны) саклау хезмәтләренә түләү;

күчемсез мөлкәтне (торак булмаган бинаны) иминләштерү хезмәтләренә түләү;»;

1.5 пунктның дүртенче абзацында «унҗиденче» сүзен «егерме беренче» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Субсидия бирү нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге субсидия бирү нәтиҗәләре кулланыла:

Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыяте үсеше турында аналитик мәгълүмат әзерләү – кимендә бер;

«Грант конкурсы» автомат мәгълүмат системасында (https://грантытатарстан.рф) (алга таба – «Грант конкурсы» АМС) профилактика эшләрен башкару – кимендә ике;

массакүләм мәгълүмат чараларында (яки социаль челтәрләрдә) субсидия алучы эшчәнлеге һәм грантлар бирү конкурсларын үткәрү турында кимендә биш мәгълүмат бирү характерындагы хәбәрләр бастырып чыгару;

коммерциягә карамаган оешмалар өчен «Грант конкурсы» автомат мәгълүмат системасында грантлар бирүгә заявкалар формалаштыру буенча консультацияләр оештыру – кимендә 60 консультация;

экспертлар өчен «Грант конкурсы» автомат мәгълүмат системасында коммерциягә карамаган оешмаларның грантлар бирү турындагы заявкаларына экспертизалар үткәрү буенча консультацияләр оештыру – кимендә 20 консультация;

гражданлык җәмгыяте институтларын үстерү чараларын үткәрү – кимендә биш чара.

Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.»;

5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«күчемсез мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсе.»;

8.6 пунктының беренче абзацында «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 30 декабрь, 1462 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 ел, 27 март, 358 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 ел, 18 март, 156 нчы карарының 3 пунктлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 30 декабрь, 1462 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 ел, 11 октябрь, 878 нче карары.

3. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин